| | |
|---|---|
| СОВЕТ<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО<br>ОБРАЗОВАНИЯ<br>«ТИМЯШЕВСКОЕ<br>СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ»<br>ЛЕНИНОГОРСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЛЕНИНОГОРСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>«ТИМӘШ<br>АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»<br>МУНИЦИПАЛЬ<br>БЕРӘМЛЕГЕ<br>СОВЕТЫ |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

2025 елның 25 ноябре Тимәш авылы № 11

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Тимәш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының «Җир салымы турында» 2020 елның 15 октябрендәге 7 номерлы карарына (07.11.2023 № 43, 06.06.2024 № 13, 08.07.2025 № 20 үзгәрешләр белән) үзгәреш кертү хакында

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Тимәш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы белән, гражданнарның аерым категорияләренә җир салымы буенча бирелә торган ташламаларны Россия Федерациясе Салым кодексы нормаларына туры китерү максатында, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Тимәш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советы КАРАР БИРДЕ:

1.Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Тимәш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының «Җир салымы турында» 2020 елның 15 октябрендәге 7 номерлы карарына (07.11.2023 № 43, 06.06.2024 № 13, 08.07.2025 № 20 үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешне кертергә:

3 пунктның дүртенче абзацын төшереп калдырырга.

2.Әлеге карарны түбәндәге адрес буенча урнашкан мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә: Татарстан Республикасы, Лениногорск районы, Тимәш авылы, Утыз Имәни ур., 71д йорт-җирле үзидарә бинасы, Киров ур., 26 йорт – җирле мәдәният йорты бинасы, нефть үткәрүчеләр ур., 20 йорт - Ромашкино РНУ БПО утырышлар залы, Киров ур., 1а йорт – «Ласточка» балалар бакчасы бинасы, Урман ур., 20 йорт, Урман ур., Урман ур., 33, Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында (https://leninogorsk.tatarstan.ru) «Авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (https://pravo.tatarstan.ru)бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар Россия Федерациясе Салым кодексының 5 статьясы нигезендә үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплыгымда калдырам.

«Тимәш авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге башлыгы,
Совет рәисе Х.Х.Сөләйманова